Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Колшәрип авыл Советы

КАРАР

20 май 2025 ел №108

Әлмәт муниципаль районының Колшәрип авыл Советы «Әлмәт муниципаль районының Колшәрип авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең, җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында» 2018 елның «24» августындагы 57 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнарының, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең рәисләренең, рәис урынбасарларының, аудиторларның хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 елның 14 апрелендәге 228 номерлы карары нигезендә, шулай ук хокукый мониторинг тәртибендә

Колшәрип авыл Советы КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Колшәрип авыл Советының «Әлмәт муниципаль районы Колшәрип авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең, җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында» 2018 елның «24» августындагы 57 номерлы карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Колшәрип авыл Советының 2018 елның 10 декабрендәге 60 номерлы, 2020 елның 18 декабрендәге 10 номерлы, 2022 елның 27 октябрендәге 46 номерлы 2022 елның 14 декабрендәге 52 номерлы, 2024 елның 26 июнендәге 89 номерлы, 2024 елның 12 декабрендәге 97 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «Әлмәт муниципаль районы Колшәрип авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең, җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары» (алга таба- Тәртип) кушымтасының I бүлегенең 4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Башлыкның, башлык урынбасарының хезмәт өчен түләү чыгымнары күләме ай саен акчалата бүләкләүне түләү өлешендә хезмәт өчен түләүнең

унберенче төркеменә кертелгән муниципаль берәмлекләр башлыклары өчен елына 16,85 айлык акчалата бүләкләүне, аларның урынбасарлары өчен елына 17,27 айлык акчалата бүләкләүне тәшкил итә торган нормативтан артыграк була алмый.»;

1.2. тәртипнең II бүлегенең 6 пунктындагы 5 пунктчасында «41 процент» сүзләрен «58 процент»сүзләренә алмаштырырга;

1.3. карарга 1 нче кушымтадагы таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлмәт муниципаль районы Колшәрип авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәре

| Вазыйфаның исеме | Вазыйфаи оклад (Хезмәт өчен түләүнең 11 төркеме) |
|---|---|
| Башкарма комитет җитәкчесе | 23 084 |
| Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары | 22 622» |

1.4. карарга 2 нче кушымтада таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлмәт муниципаль районы Колшәрип авыл җирлегенең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларын ай саен акчалата бүләкләү күләмнәре

| Вазыйфаның исеме | Айлык акчалата бүләкләү күләме (Хезмәт өчен түләүнең 11 төркеме) |
|---|---|
| Башлык | 23 091 |
| Башлык урынбасары | 16 594» |

2. Әлеге карарны Колшәрип авылы, Тукай урамы, 50 йорт торак пунктлар территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә игълан ителгәннән соң үз көченә керә һәм 2025 елның 1 маеннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Колшәрип авыл
җирлеге башлыгы А.Ф. Кәшәфетдинов